ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«19» майя 2021 ел** **№ 333**

**Биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан аларны карап чыгу буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм аларга тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан аларны карау буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан аларны карап чыгу буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне (1 нче кушымта).

2.2. Биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан аларны карап чыгу буенча ведомствоара комиссия составын (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

Татартстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
19.05.2026 ел, № 333
карарына 1 нче кушымта

**Биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан аларны карап чыгу буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан аларны карап чыгу буенча комиссиянең гомуми нигезләмәләрен, төп функцияләрен, эшчәнлеген билгели (алга таба - Комиссия).

1.2. Комиссия Арча муниципаль районы башкарма комитеты каршында Арча муниципаль районы территориясендә эксплуатацияләнә торган биналарга һәм корылмаларга, аларның милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, визуаль карап чыгу (алга таба – Карап чыгу) максатыннан төзелгән киңәшмә орган булып тора, моңа әлеге биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә федераль законнар белән дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру каралган очраклар керми.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка хокукый актларына, Арча муниципаль районы муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең вәкаләтләре

2.1. Комиссия вәкаләтләренә тиешенчә техник хезмәт күрсәтү максатыннан биналарның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм күренеп тора торган кимчелекләрен һәм зарарланган урыннарын фотога төшереп, визуаль күзәтүләр оештыру һәм үткәрү керә (ярыклар, протечка, тимер-бетон элементларда саклагыч катлам кубу, металл элементларда күгәрек барлыкка килү, тоташкан һәм беркетелгән урыннарның пландагы торышыннан тайпылу, кәкрәю һ. б.)

2.2. Комиссиянең вәкаләтле затлары карап чыгылачак объект турында эксплуатация өчен җаваплы зат бирелгән мәгълүматны (төзелеш вакытын, эксплуатацияләү вакытын, инженерлык җиһазлары күләмнәрен-планлаштыру һәм системаларының гомуми характеристикасын) өйрәнәләр, шул исәптән алып бару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.25нче статьясындагы 5 өлешендә каралган бинаны, корылманы эксплуатацияләү журналы белән танышалар.

2.3. Комиссиянең вәкаләтле затлары бинаның, корылмаларның техник торышын бәяләү һәм тиешенчә техник хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка чаралар үткәрә.

2.4. Комиссия бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы, карала торган бинага, корылмага керү мөмкинлеген тәэмин итүче затны (аның вәкаләтле вәкилен) катнашуга җәлеп итә.

Кирәк булганда, Карап чыгуда катнашуга проект һәм эксперт оешмалары вәкилләре, мөрәҗәгать итүче җәлеп ителергә мөмкин.

## 3. Комиссияне төзү һәм аның эш тәртибе

3.1. Комиссия Арча муниципаль районы башкарма комитетының һәм аның карамагындагы муниципаль учреждениеләрнең тармак (функциональ) органнары, башка структур бүлекчәләре вәкилләреннән Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

3.2. Комиссияне - рәис, ә ул булмаганда - Комиссия рәисе урынбасары җитәкли.

3.3. Комиссия рәисе:

а) Комиссия эшен оештыра;

б) Карау уздыру датасын, вакытын, урынын билгели;

в) Карау уздыру срокларын озайта.

3.4. Комиссия рәисе урынбасары:

а) Комиссия компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә;

б) Комиссия рәисе йөкләмәләрен үти.

3.5. Комиссия секретаре:

а) Арча муниципаль районы башкарма комитетының Карап чыгу рәвешендә тикшерү уздыру турындагы карары проектын әзерли;

б) кирәкле материалларны Карап чыгу әзерләү эшен җайга сала;

в) Комиссия әгъзаларына һәм әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән затларга Комиссияне үткәрү датасы, вакыты, урыны турында аны уздыру датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча заказлы хат белән почта аша яисә аны алу фактын теркәргә мөмкинлек бирә торган башка ысул белән Комиссия тарафыннан билгеләнгән яисә гаризада күрсәтелгән адреска хәбәр итә;

г) бинаны, корылмаларны карау актын (карау мөмкинлеге булмау турында акт) рәсмиләштерә;

д) Комиссия эше алып баруны, Комиссия документларының төп нөсхәләрен саклауны тәэмин итә;

е) Комиссия рәисенең башка йөкләмәләрен үти.

Комиссия секретаре булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе билгеләгән Комиссия әгъзаларының берсе башкара.

3.6. Комиссия анда әгъзаларның кимендә яртысы катнашканда Карап чыгу үткәрергә хокуклы.

3.7. Комиссия үз эшчәнлеген алар Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә, биналарда, корылмаларда авария хәлләре барлыкка килү яки биналар, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында мәгълүмат кергәндә күчмә визуаль Карап чыгу рәвешендә гамәлгә ашыра.

Карап чыгу Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары рәвешендә кабул ителгән тиешле карар нигезендә үткәрелә.

3.8. Карап чыгу Арча район Советының «Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан биналарны, корылмаларны карап чыгуны уздыру тәртибен раслау турында» ________________ ел, №__карары белән билгеләнгән тәртиптә аларның техник торышын бәяләү һәм тиешле техник хезмәт күрсәтү максатларында үткәрелә.

3.9. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Арча муниципаль районының инфраструктура үсеше бүлегенә йөкләнә.

Татартстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
19.05.2021 ел, №333
карарына 2 нче кушымта

**Капиталь төзелеш объектларын карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Мөхәрәмов Рәсүл Ринатович | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, Комиссия рәисе |
| Галимуллин Илшат Әхәтович | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, рәис урынбасары |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Фазыйлов Радик Рашатович | Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| Мөхәмәдияров Рамил Данилович | Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы; |
| Әюпов Илфар Илдар улы | Арча муниципаль районы башкарма комитетының "Мәдәният идарәсе" МУ башлыгы |
| Габделгазизов Ильяс Нурсилович | Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |
| Салкова Эльвира Валентиновна | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач муниципаль районнарында ТО башлыгы (килешү буенча) |
| Гатиятова Елена Николаевна | «Татарстан Республикасының техник инвентаризация бюросы» АҖ бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сафин Рөстәм Роальдович | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМның УНД һәм ПР ДУ идарәсенең Арча һәм Әтнә муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм ПР районара бүлеге башлыгы |

Искәрмә: Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл иткәндә, комиссия составына капиталь төзелеш объектлары урнашкан территориядәге авыл җирлекләре башлыклары кертелә.